СОВЕТ
СТАРОТЯБЕРДИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ИСКЕ ТӘРБИТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

02 декабрь 2021 ел. Иске Тәрбит ав. № 14

**Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органнарына тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Иске Тәрбит авыл җирлеге Уставы нигезендә Иске Тәрбит авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органнарына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча төзекләндерү өлкәсендәге вәкаләтләрнең тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектын килештерү буенча, җир эшләрен башкаруга рөхсәтләр бирү буенча бер өлешен тапшырырга.
2. Әлеге карарны карау өчен Кайбыч муниципаль районы Советына җибәрергә.
3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә Кайбыч муниципаль районы Советы карарын алган вакыттан алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны тапшыру турындагы килешү төзүгә як булып чыгарга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске Тәрбит авыл җирлеге Интернет челтәрендәге рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ веб адресы буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
5. Әлеге карар басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы В.Г.Тимофеев